**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Дүсем авылы торак пунктында
2024елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 20 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Дүсем авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Дүсем авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, өлкән, ялгыз яшәүче затлардан, Украина территориясендә хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Дүсем авылы зиярәтына отбойный чүкеч сатып алу;
2) Дүсем авылында "МТЗ-82" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;
3) Дүсем авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампочкалар һәм яктырткычлар сатып алу);
4) Дүсем авылында массакүләм чаралар (Сабантуй) үткәрү өчен бүләкләр алу;
5) Җәйге чорда авыл территориясен чабу өчен триммерга ГСМ алу һәм договор нигезендә эш башкаручыга түләү;
6) Дүсем авылында кышкы чорда кар чистарту өчен ротор сатып алу ;

3. Әлеге карарны Ләшәү Тамак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.З.Хабибуллин